**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Базарлы Матак авылы **КАРАР**

2022 елның 28 июле 271№

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органының хисап чорында "Мәгариф дәрәҗәсе" күрсәткече составына керүче "2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеге" күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле мәгълүматларны җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлек регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 21 июлендәге «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 474 номерлы, 2021 елның 4 февралендәге «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 68 номерлы Әмерләре нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органының хисап чорында "Мәгариф дәрәҗәсе" күрсәткече составына керүче "2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеге" күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле мәгълүматларны җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлек регламентын расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ җитәкчесенә йөкләргә.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **С.Н. Балакирев**

2022.28.07, 271№

карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органының хисап чорында "Мәгариф дәрәҗәсе" күрсәткече составына керүче "2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеге" күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле мәгълүматларны җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлек регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Регламентны җайга салу предметы.

Әлеге Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органының хисап чорында "Мәгариф дәрәҗәсе" күрсәткече составына керүче "2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеге" күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле мәгълүматларны җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлек регламенты Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 21 июлендәге «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 474 номерлы, 2021 елның 4 февралендәге «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 68 номерлы Әмерләре, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 3 апрелендәге «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрен исәпләү методикасын раслау, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 542 номерлы карары,Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге «Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасы турында» 920 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 18 апрелендәге «Контроль» модуленең бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасына үзгәрешләр кертү турында» 361 номерлы карары нигезендә эшләнгән һәм җирле үзидарә органының хисап чорында "Мәгариф дәрәҗәсе" күрсәткече составына керүче "2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеге" күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле мәгълүматларны җыю һәм мониторинглау тәртибен билгели (алга таба - декомпозацияләнгән күрсәткеч).

мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү хезмәтләрен алучы 2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар саны;

дәүләт яисә муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында урын бирү өчен исәпкә куелган 2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар саны.

Әлки муниципаль районында декомпозия күрсәткечләрен җыйган һәм мониторинглаган өчен җаваплылык үзәге булып «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ (алга таба - мәгариф бүлеге) тора.

1.2. Белешмә мәгълүматы.

Әлеге Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органының хисап чорында "Мәгариф дәрәҗәсе" күрсәткече составына керүче "2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеге" күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле мәгълүматларны җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлек регламенты максатлары өчен Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 3 апрелендәге «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрен исәпләү методикасын раслау, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 542 номерлы карары күрсәткечне исәпләү методикасында билгеләнгән терминнар кулланыла.

## 2. Исәп-хисап стандарты, мәгълүматлар җыю һәм бирү тәртибе

декомпозияләнгән күрсәткечне исәпләп чыгару өчен түбәндәге мәгълүматлар кулланыла:

мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү хезмәтләрен алучы 2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар саны;

дәүләт яисә муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында урын бирү өчен исәпкә куелган 2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар саны.

Мәгариф бүлегенең җаваплы хезмәткәре мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм кабул итү буенча хезмәтләр күрсәтүче оешмалардан хисап чорында югарыда күрсәтелгән күрсәткечләр җыюны гамәлгә ашыра.

Муниципаль район буенча мәгълүмат Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы адресына Татарстан Республикасының электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасында рәсми хат белән бирелә.

## 3. 3. Мәгълүмат составы, вакыты бирү һәм тәэмин итүчеләр

3.1. Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм кабул итү буенча хезмәтләр күрсәтүче әлеге оешмаларны күрсәтү рәвеше Таблицада тәкъдим ителгән.

Таблица

Мәктәпкәчә белем бирү хезмәтләрен алучы 2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар саны

| т/б № | Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм кабул итү буенча хезмәтләр күрсәтүче оешма исеме | Үлчәү бердәмлеге (кеше) | Мәгълүмат бирү вакыты квартал саен хисаптан соң килүче айның 1 числосына кадәр. | Дәүләт яисә муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында урын бирү өчен исәпкә куелган 2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар саны | Мәктәпкәчә белем бирү хезмәтләрен алучы 2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар саны |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |